

АЛАР САЙЛАДЫ

Мәскәү Кремлендә – тарихи вакыйга

> 2



ОНЛАЙН КИБЕТ

Якын киләчәктә кибеткә чыгып әйбер сатып алулар онытылырга да мөмкин

> 2

ТАТАРЧА УКЫЙМ!

Казанның 2 нче гимназиясендә Тукай телендә белем бирү ничек бара?

> 3

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ

Татарстан Республикасы бюджеты турында

> 5–44

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 144 (28917) | Шимбә | 1 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Өлкәннәр көне

Ә ЙӨРӘККӘ ҺАМАН 18!

Әллә ни күп кирәкми үзләренә. Оекбашлары да җитәрлек, аулыклары да күп. Олыгайган көндә кадерле, кирәкле булып яшиселәре генә килә өлкәннәрнең. Берәр язма әзерләргә өйләренә барсаң, яннарыннан җибәрәселәре килми. Аралаша торгач, шуны аңлыйсың – олыларга бер җылы сүз җитә! Ә бит картлык һәркемгә киләчәк.

Картлык дигәннән, өлкәннәрнең берсе дә бу сүзне әйткәнне яратмый. Казанда яшәүче Роза Садыйкова, сүз башлаганчы ук, ул сүзне әйтмәгез, дип кисәтеп куйды.

– Картаю турында уйлаганым да юк, – ди 91 яшьлек Роза ханым. – Мин бит әле дә эшләп йөрим. Дөрес, түләүле эш түгел. Әмма мин әле кирәк. Киңәшмәләр, очрашулар булса, чакыртып алалар. Үз яшемә үзем дә ышанмыйм. Йөрәгем унсигездә кебек. Өйдә генә утырсам, бәлки күптән карт аюга әйләнгән булыр идем. Әмма мине эш бәхетле итте. Картлыктан да коткарды, гомеремне дә озайтты. Беләсезме, эштән курыккан кешенең гомере озын булмый аның. Кешеләр янында булу, аралашу кирәк. Яшьләр белән дә еш очрашып торам, шуңа күрә картая да алмыйм. Әбигә әйләнәсем килми. Әле минем йөз яшькә җитәргә исәп.

Роза Садыйкова Бөек Ватан сугышы вакытында кырда эшләгән. Урак урган, көлтә бәйләгән. Илләр тынычлангач, Совет сәүдәсе институтын тәмамлаган. Күп еллар хисапчы, аннары кибет директоры булып эшләгән. Пенсиягә чыкканчы, 20 елдан артык Казан сәүдә техникумында балалар укыткан. Пенсиягә чыккач та иҗтимагый оешмалар эшчәнлегенә кушыла, әле дә Татарстанның сугыш ветераннары һәм хәрби хезмәт иҗтимагый оешмасы әгъзасы, Ватанны саклаучыларның исемнәрен мәңгеләштерү буенча иҗтимагый комиссия рәисе булып эшли. Ирен моннан 33 ел элек югалткан. Алар ике ул үстергәннәр. Бүген уллары һәм оныкларына сөенеп яши.

Республикада яшәүче өлкәннәргә «Демография» илкүләм проекты кысасында ярдәм итәләр. Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проектын гамәлгә ашыру кысасында өлкән яшьтәге кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү алымнары үзгәртелә: барлык районнарда озак вакытлы карау системасы гамәлгә ашырыла.

– Урын өстендәге өлкәннәрне караучылар өчен «Тәрбия мәктәпләре» оештырылды, кирәкле махсуслаштырылган җиһазлар сатып алынды. Авыру кешеләрне тәрбияләүче туганнарын һәм белгечләрне шул җиһазлар белән эшләргә өйрәтер өчен укытабыз. Шушы максатларда 2019 елдан 2022 елга кадәр 6,5 мең кеше белем алды, – ди министр. – Республикада инде 6 ел рәттән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны гаиләгә тәрбиягә алу кебек социаль хезмәт күрсәтү формасы эшли. Хәзерге вакытта 33 муниципаль районда 34 шундый гаилә булдырылган. Диспансеризация узу һәм скринингլар ясау өчен 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына китерү буенча хезмәт уңай бәя алды. 2019 елдан 2021 елга кадәр медицина оешмаларына 146,2 мең өлкән кеше китерелгән. Агымдагы елда 56,5 меңнән артык өлкән яшьтәге авыл кешесе әлеге хезмәттән файдаланачак. «Демография» илкүләм проекты шулай ук 50 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнарга, шулай ук пенсия алды яшендәге кешеләргә бушлай һөнәри белем алу – квалификацияләрен күтәрү яки хәтта яңа һөнәр үзләштерү мөмкинлеге бирде. 2021 елда өстәмә һөнәри белем алу хокукыннан 3501 кеше файдаланган.

Дөрестән дә, безнең өлкәннәр тик утыра белми алар. Үзләре дә, хәрәкәттә – бәрәкәт, диярга ярата. Көнозын утырып эшләүчеләрне, кулларына телефон тотып шуңа багынып утыручыларны сүгеп тә ташлый алар. Казанда яшәүче 71 яшьлек Лидия Горохова олыгайган көнендә спорт белән дуслаша.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ахыры 3 нче биттә >

САН

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, республикада пенсия чиген узган 914 мең кеше яши. Йөз яшькә җиткән 157 әби-бабай бар. Татарстанның иң өлкән ир-атына – 102 яшь. Ул Питрәчтә яши. Ә иң өлкән хатын-кызга май аенда 107 яшь тулган. Ул Зәйдә гомер итә.

Акча арта

Киләсе елда бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие күләме 23011 сумга җитәчәк. Аны, кеременең нинди булуына карамастан, барлык гаиләләр алачак. Бирегә мохтаҗлык исәпкә алынмый. Башка түләүләр дә арта. Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, яшь ярымга кадәр бала карау буенча пособиенең максималь күләме аена 33281 сумга (31282 сум булган) җитәчәк. Минималь күләме 7677 сумнан 8629 сумга кадәр артачак. «Больничный»ның иң зур күләме – аена 83204 сум, декрет акчасының иң күп күләме 383179 сум (бер айга – 83204 сум) тәшкил итәчәк.

2023 елда Социаль фонд бюджетыннан вакытлыча эшкә яраксызлык буенча түләүгә барлыгы 445 миллиард сум бирү күздә тотыла. Исегезгә төшерәбез: киләсе елда ана капиталы беренче балага – 589,5 мең сум, икенчесенә 779 мең сум булачак.

Башкортлар күбрәк ала

Күчемсез милекне Татарстаннан иң күп сатып алучылар – Башкортстан һәм Ульяновск өлкәсе халкы. Росреестр идарәсенә гыйнвар аеннан августка кадәр башка төбәкләрдә яшәүчеләрдән республикада сатып алынган милекне теркәүгә 3490 гариза кабул ителгән.

Татарстандагы күчемсез милеккә мөкиббән китүче 10 төбәк исемлегенә шулай ук Самара өлкәсе, Чуашстан, Мәскәү өлкәсе, Мәскәү, Удмуртия, Ханты-Манси автономияле округы, Мари Иле һәм Түбән Новгород өлкәсе кергән. 3490 гариза арасыннан 1224е Казаннан торак сатып алуга бәйле.

Авыл өчен тырышу

2019–2021 елларда Татарстанда «Авылларны комплекслы үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга 9,6 миллиард сум җәлеп ителгән. Акча авылда яшәүчеләрнең торак шартларын яхшыртуга, аларны социаль объектлар, инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итүгә тотылган. Программа нигезендә, республикада 1,2 мең гаилә өчен барлыгы 70 мең кв. метр торак мәйданы төзелгән, 990 корылма төзекләндерелгән, 57 чакрым озынлыкта юл салынган.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Марсель Мәхмүтов әйтүенчә, республикада барлыгы 3,9 миллион кеше яши. Шуның 23 проценты (900 мең чамасы) – авылларда. Авылларны комплекслы үстерү программасы нигезендә муниципалитетлар һәм җирлекләр күркәмләнә, авылда яшәүчеләрнең тормышы яхшыра.

Быел программа буенча Татарстанга 1,7 миллиард сум акча бирү күздә тотылган. Шуның 33,6 миллион сумы торак шартларын яхшыртуга тотылачак. Бу 17 гаилә өчен 1,1 мең кв. метр торак мәйданын файдалануга тапшыру мөмкинлеге бирәчәк. Наем килешүе буенча торак төзүгә 159,2 миллион сум каралган. Барлыгы 53 гаиләгә 3,8 мең кв. метр торак мәйданын булдыру күздә тотыла.

COVID-19

Җиңел сулар чак түгел

Бер атна эчендә Татарстанда коронавирус белән авыручылар саны 20 процентка кимегән. Соңгы бер тәүлек эчендә ковид йоктыруның 535 очрагы ачыкланган. Шулай да белгечләр, тынычланырга иртәрәк, дип кисәтә. Ник дигәндә, хәзер коронавирус кына түгел, грипп, ОРВИ кебек башка төр вируслы авырулар да котырган чак.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина сүзләренә караганда, бер атна эчендә республикада коронавирус йоктыруның 5,586 очрагы теркәлгән. «Бу узган атнага караганда 19 процентка кимрәк. Шул рәвешле без яңа коронавирус инфекциясе белән авыручылар саны кимегән беренче атнаны теркибез», – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Авдонина сүзләренә караганда, бер атна эчендә республикада кискен инфекция (ОРВИ) белән авыручылар саны да 2 процентка кимегән. Татарстан халкын вакцинацияләү, җәмәгать урыннарында битлек кию, кулларны юып йөрү, авыручылар белән аралашудан баш тарту хисабына инфекцияле авырулар йоктыру очраклары алга таба да артмас, дип өметләнә белгеч.

Хәзер барлык төр вируслы авырулар котырган чорга аяк бастык. Аларга каршы иммунитет булдыру өчен белгечләр вакцина ясатырга киңәш итә. Хәзерге вакытта республикада коронавируска каршы вакцина ясаткан 2,78 миллион кеше исәпләнә. Гриппка каршы прививканы исә ярты миллион кеше ясаткан. Соңгы арада республикада пневмококка каршы вакцина да ясата башлаганнар. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, әлеге прививка ОРВИ белән авырып терелгәннәрдә күзәтелгән бактериаль пневмониядән саклый.

– Вакцина ясату – бу чирдән саклануның иң нәтиҗәле юлы. Әлеге прививка кечкенә сабыйларга 2,4 һәм 15 айлык чакта, 2–5 яшьлек балаларга ясала. Аны хроник үпкә авырулары булган 60 яшьтән олырак кешеләр дә ясата ала, – ди министр урынбасары.

Жаворонков сүзләренә караганда, пневмококка каршы вакцинаны ясату өчен участок табибына мөрәҗәгать итәргә кирәк. «Вакцина беткән булса, сезне чиратка куячаклар. Аны озак көтәргә туры килмәячәк. Вакцина запаслары тулыландырып торыла», – диде Жаворонков.

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Россия Дәүләт Думасы Финанс базары буенча комитет рәисе:

Кайбер мәгълүматлар күрсәткәнчә, криптовалюта әйләнеше буенча без икенче-өченче урында торабыз. Бу – әгәр дә хокукый шартлар тудырылса, аны куллану буенча шундук эшне башлап җибәрергә мөмкинлек бар дигән сүз. Мин ниндидер проблемалар килеп чыгар дип уйламыйм.

«Парламентская газета»га биргән әңгәмәдән

ҖӘЙГЕ ЯЛГА ТОТЫЛГАН АКЧА

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре ачыклаганча, быел Россиядә яшәүчеләр уртача 30 көн ял иткән. Алар шулай ук ялга тотылган акча күләмен дә исәпләп чыгарган.

УРТАЧА СУММА

1 кешегә >> 38605 сум

Кереме югары булганнар.....55194 сум

Кереме уртача булганнар....35953 сум

Кереме аз булганнар...........21653 сум

Ялгышлар булмасын

Татарстан прокуратурасында өлешчә мобилизация чорында хәрби хезмәткә чакыру өлкәсендәге мәсьәләләр буенча тәүлек әйләнәсендә махсус «кайнар линия» эшли башлаган. Үзегезне борчыган сорауларны 8 (843) 291-19-25 (мөрәҗәгатьләрне кабул итү төркеме), 8 (843) 291-18-81 (дежур прокурор) телефоннары аша эш көннәрендә 9.00–18.00 сәгатькә кадәр, ял көннәрендә – 18.00–9.00 сәгатькәчә бирергә мөмкин. Татарстан прокуроры өлкән ярдәмчесе Руслан Галиев әйтүенчә, барлык мөрәҗәгатьләр каралып, тиешле чаралар күреләчәк.

Сүз уңаеннан, Россия Президенты Владимир Путин Иминлек советы утырышында өлешчә мобилизация вакытындагы барлык ялгышлыкларны төзәтүне, алга таба хаталанмауны таләп итте. «Хәрби тәҗрибәгә ия булучылар чакырыла. Бу таләп тайпылышсыз үтәлергә тиеш», – диде Президент. Аның әйтүенчә, һәрбер очракны тикшереп, ялгыш мобилизацияләнүчеләрнең һәммәсен кире өйләренә кайтарырга кирәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Наданлык – җинаятьме?

Кешелек җәмгыяте, тарихы берничә мең ел белән генә билгеләнсә дә, төрле өлкәләрдә шактый олы күләмдәге гыйлем һәм тәҗрибә туплаган. Гыйлем багажы бигрәк тә соңгы йөз елда нык тулыланды. Медицина өлкәсендә ярылган яңа белемнәр, галәмгә кагылышлылары, төгәл фәннәрдә, техника белән технологиядә туганнары.

Безне баеткан ул гыйлемнәр – шул өлкәдәге белгечләр карамагында. Аларны бар кеше дә белә алмый. Тиеш тә түгел. Автомобиль двигателенең ничек эшләвен бүген рульгә утырган һәр биш кешенең берсе генә белә, диләр. Кулыннан смартфонын төшермәгән бүгенге адәми затларның йөздән, хәтта меңнән бере генә аның төзелешен, эш принцибын бераз чамалый. Бөтен кешенең дә микроэлектроника белгече булып китүенә хаҗәт тә, кирәклек тә юк. Кулланучы шуның өчен дә кулланучы ул: файдалана белсә, шул җиткән.

Тик дөньяда гуманитар белем дә бар бит әле. Менә анысы белән хәл катлаулырак. Аңа таләпләрне башкачарак куясы килә. Гуманитар фәннәрне җирдә яшәгән һәркем билгеле бер дәрәҗәдә үзләштерергә тиеш түгел микән? Алар күпчелек очракта аңлаешлы һәм чагыштырмача җиңел булган өчен генә түгел. Кеше үзе яшәгән тирәлекне, җәмгыятьне, үзенең андагы урынын азмы-күпме аңласын, үткәнен белсен өчен. Кеше чын кеше булсын өчен. Гавам ул өлкәне белгәндә тормышның башка – күпкә күркәмрәк, мәгънәлерәк булачагы да аңлашыла кебек. Классикларны укып чыгу гына да кешенең офыкларын күпкә киңәйтергә сәләтле бит.

Әммә... Арабызда гомере буе өч китап та укымаган затлар да җитәрлек. Шул ук тарих, җәмгыять белеме, урта мәктәп тәкъдим иткән башка фәннәр дигәндә дә гыйлем йортыннан бернәрсә дә алып чыкмаган чи наданнар күп. Күпләрнең зиһене ялкау, кызыксынуы юк, кемдер өчен мәгълүмат – авыр йөк, баш катыру. Хәтсез кеше: «Артык белү миңа нәрсәгә, ул керемне арттырмый, байлык китерми бит», – ди. Капитализм бәндәне матди байлыкка мөкиббән итә, рухи байлык бик күпләр өчен унынчы урында.

Мондый вазгыять – фаҗига булмаганда да бәла. Мондый хәл, ахыр килеп, ВЦИОМ үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә, әгъни илдәге халыкның өчтән беренең: «Кояш Җир тирәли әйләнеп йөри», – дип белүенә, бүгенге башка бик күп сансызлыкларга илтеп җиткерә. Әйтеләгәннәрдән чыгып, «капиталистик мөнәсәбәтләр – гомуми гыйлемлек, гуманитар белемнең дошманы» дигән нәтиҗә дә чыгарып булыр иде. Шул ук техник белем, техник прогресс табыш арттыру инструменты булган җәһәттә дә.

Совет чорының соңгы елларында ярылган гыйлемлек культы, китап культы кыска гомерле булды. Без яңа стройга керел киттек. Комсызлык, табыш һәм куллану культы беренче урында торган стройга. Куллану җәмгыятендә яшәп, бар нәрсәне акча призмасы аша үткәргәндә, Җир Кояш тирәли әйләнсә ни дә, киресенчә булса ни – көндез якты, кич караңгы икән, шул җиткән. Күпләр өчен гыйлемнең баерга ярдәм итә торганы, белем димәсән, хәтере калырдае гына чын гыйлем-мәгърифәт санала башлады. Шариковлар саны артты. Шул ук бизнесменнар арасында да. Әлбәттә, Тын океанның планетада иң зур сулык икәнен, Бөек Француз революциясенең XVIII гасыр азагында булганын, водородны Генри Кавендиш ачканын белергә карап табышың артмый, сиңа беркем дә дивидендлар язмый, премия билгеләми. Тик кеше дигәнең шуның өчен дә кеше – аның гомуми гыйлем запасы, үзе яшәгән дөнья, биосфера турында, планетаның географиясе, тарихы хакында мәгълүмат булырга тиеш. Никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшы. Башкача адәми зат алга бара алмый, ә деградация һәммәбезне сагалый, ул янәшә генә.

Бездәге обывательнең уннан тугызы «Нәрсә ул гражданлык җәмгыяте?» дигән сорауга да җавап бирә алмый, димәк, аның кирәклеген, мөһимлеген күрми. Үзе яшәгән илгә, төбәккә кагылган тарихи даталар, вакыйгалар да аңа һич кирәк түгел. Үткәннең бөек акыл ияләре, философлар, алар әйткән фикерләр дә бары буш җөмләләр аңа. Ә инде нинди дә булса анализ, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләр – гомумән дә параллель дөнья. Аның күпкә «мөһимрәк» гамәлләр башкарысы – акча «ясыйсы», табасы, кирәген дә, кирәкмәгәнен дә үзенә ташыйсы бар. Ничәнче булып килүенә карамастан, «күсе чабышы» дип аталган узышта катнашасы бар.

Кызыксынмау, караңгылык, наданлык. Борынгыдан, Буддадан ук калган шундый сүз барлыгы мәгълүм: «Халыктагы наданлык бала гөнә түгел, ул – җинаять». Килешми мөмкин түгел. Хак булса, һәр ун җинаятьчене тугызы интеллект, эрудиция дигәндә тау кушышында яшәгән борынгы бабаларыбыз янәшәсендә тора. Монысы – бер бала. Тагын да зуррак бәла – наданда намус, әхлак дигән, кешене кеше иткән сыйфатлар гыйлемле белән чагыштырганда күпкә сай. «Наданлык – җинаять». Кешелек монарчы кичереп килгән бик күп михнәтләрнең төбендә гавамдагы гуманитар караңгылык, гыйлемсезлек ятуын күп галимнәр, тарихчылар әйтә. Каннлы бәрелешләр нилектән ярала? Чал тарихтан билгеле – патшалар халыкның сарык көтүеннән аз аерылганын, аны теләсә ни рәвешле файдаланып булганын яхшы белгәнгә туган алар һәрчак. Сәяси уеннарын уйнаганда дошман табып, ярым томана гавамны аның дошман икәненә ышандыра алганга. Букса кайгысыннан башканы белмәгәннәрне ник адаштырмаска, саташтырмаска, файдаланмаска? Файдаланганнар һәм файдаланалар. Бары надан, мингерәүләр арасында гына халык хисабына, аны изеп, савып яшәүче тираннар, залимнәр яралган һәм ярала.

Төптән уйлаганда шунысы да бик ачык: бәндәдәге наданлык өч тиенлек кыйммәте булмаган әйберләрне кыйммәтле, затлы итеп күрсәтә, иллюзиядән чынбарлык ясый, чын максатлар урынына ялганын тудыра, адәми затны бутый, ялгыштыра. Бәһасез нәрсәләр артыннан чаптыра. Йөз процент наданны бу дөньяда бары бик әйбер генә кызыксындыра, диләр. Ул да булса – ашау, йокы, секс, тамаша һәм үзеңне саклау (самозащита). Шуның белән шул. Андый тормыш белән яшәү кирәдән кыргыйлыка, тау кушышына кайтуга тиң түгелме?

«Иң олы байлык – акыл, иң олы мирас – тәрбия, иң зур фәкыйрьлек – наданлык», – дигән бер бик акыллы кеше. Җирдә яшәгәннәрнең абсолют күпчелегендә гыйлемгә ихтыяҗ ризыкка ихтыяҗ кебек көндәлек гадәткә әйләнмичә, кешелек дөньясы, ихтимал, бәхеткә ирешмәс. «Чын бәхетне бирә бары тик гыйлем генә, һәммәсе зурлап баш ия гыйлемлегә». Гыйлемгә зурлап баш ия, аңа табына белгән җәмгыятьне генә кешелек җәмгыяте дип атап буладыр ул.

РОССИЯ ГРАЖДАННАРЫ. ГОМЕРЛЕККӘ

Тарихи вакыйга

Кичә Мәскәү Кремлендә Луганск, Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләрен ил составына кушу тантанасы узды. Владимир Путин илнең көче бердәмлектә булуын искәртте, Көнбатышны сөйләшүләр өстәлөнә утырырга чакырды. Ил башлыгы чыгышының төп өлешләрен тәкъдим итәбез.

Искәртеп узыйк: 23–27 сентябрь көннәрендә Луганск, Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләрендә Россия составына кушылу буенча референдум узды. Халык үз фикерен әйтте. Шулар нигезендә әлеге төбәкләрне Россия составына кушу турында карар кабул ителде.

Ил башлыгы иң элек Кремль залына җыелучыларга һәм ил халкына мөрәҗәгать белән чыгыш ясады. Шуннан соң Луганск, Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре башлыклары яңа төбәкләрне Россия составына кертү турында Шартнамәгә кул куюда катнашты. Документны әлеге территорияләрнең башлыклары – Денис Пушилин, Леонид Пасечник, Владимир Сальдо һәм Евгений Балицкий имзалады.

Нәтиҗә

Дәүләт җитәкчесе үз чыгышында билгеләп үткәнчә, яңа төбәкләрнең Россия составына кушылуы – анда яшәгән кешеләрнең үзбилгеләнүгә хокукы да. Бу – Берләшкән Милләтләр Оешмасының уставында күрсәтелгән хокук. Владимир Путин әйтүенчә, әлеге дүрт төбәк язмышы белән Россия язмышы уртак.

– Кешеләр үз фикерен әйтте. Без бүген Луганск, Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләрен Россия составына кабул итәбез. Бу – миллионнаран кешенең ихтыяры һәм хокукы. Алар хуплау табар дип ышанам, – диде Президент.

Ил Президенты сүзләренчә, 2014 елда Украинадагы неонацистик дәүләт түнтәрелеше белән килешмәүчеләрне, туган телдә сөйләшү хокукы өчен һәлак булганнарны, үз мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен, динен, яшәү хокукын саклап калучылар мәңге хәтердә булачак. Тантанада барлык каһарманнарны бер минут тынлык белән искә алдылар.

Владимир Путинның чыгышы тарихи вакыйгаларны барлауга да бай булды. Аерым алганда, дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең соң чиккә җиткергәннәренә тукталды ул. Шул исәптән Европа илләрендә барган кризисның сәбәп һәм алшартлары да Көнбатыш хакимиятенең җавапсызлыгы булуын искәртте Президент.

kremlin.ru

Безнең гражданнар!

Аның ассызыклавынча, Донбасс халкы сигез ел дәвамында коточкыч геноцидка дучар булып яшәде. Запорожье һәм Херсон өлкәләрендә исә Россиягә карата нәфрәт уятып маташканнар. «Әммә халык сынмады. Киев хакимиятенең Көнбатыштагы хуҗалары мине ишетсен һәм моны барысы да истә калдырсын иде: Луганск, Донецк халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләренең халкы Россия гражданнары булып санала. Гомерлеккә», – диде Президент.

Владимир Путин шулай ук Киев режимын, хәрби көч куллануны туктатып, сөйләшүләр өстәленә утырырга чакырды. «Без моңа әзер һәм бу хакта бер генә әйтелмәде. Әммә Донецк, Луганск республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләре халыкларының фикере гамәлдән чыгарылмаячак. Россия аларга хыянәт итмәячәк», – диде Владимир Путин.

Россия Президенты искәрткәнчә, җимерелгән шәһәр һәм бистәләр, торак йортлар, мәктәпләр, театр-музейлар, хастаханәләр төзекләндереләчәк. Сәнәгать предприятиеләре, заводлар, инфраструктура, пенсия белән тәэмин итү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф системалары торгызылачак.

Ике арадагы мөнәсәбәт

Дәүләт башлыгы чыгышының күп өлеше Көнбатыш белән Россия арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланды. Дәүләт җитәкчесе аларны кыйммәтләрнең Россия өчен ят һәм нигезсез булуын берничә мәртәбә искәртте. Әйтик, Владимир Путин традицион булмаган мөнәсәбәтләр, бозыклык, Көнбатышның уйлап чыгарылган кагыйдәләр буенча яшәвенә басым ясады. Ул Россиянең әлеге юлдан бармаячагын әйтте.

– Көнбатыш башбаштаклыгы җимерелачәк. Бүген без, иң элек, үзебез өчен гадел һәм иреклe юл өчен көрәшәбез. Диктаторлык, деспотизм үткәндә калырга тиеш, – диде Владимир Путин.

Ил башлыгы әйтүенчә, Көнбатышка Россиянең дөнья йөзендә булуы тынгы бирми.

– Безнең мәдәният, сәнгать, чәчәк атуыбыз Көнбатышка куркыныч тудыра. Аларга Россия бөтенләй кирәкми. Ул безгә кирәк! Россия һәрвакыт Россия булып калачак. Без хәзер дә үз кыйммәтләребезне, Ватаныбызны саклаобыз! – диде Владимир Путин.

Русофобия турында

Президент, Көнбатыш русофобиясен расизм белән чагыштырырга мөмкин, дигән фикердә. Аның сүзләренчә, Көнбатыш элитасы әле дә колонизатор сыйфатын югалтмаган. Халыкларны бүлү һәм аеру аларга хас.

– Без мондый сәяси милләтчелекне һәм расизмны беркайчан да кабул итмәдек һәм кабул итмәячәкбез дә. Ә хәзер бөтен дөньяга таралган русофобияне расизм дими, нәрсә дип атарга була соң? – диде Владимир Путин.

Ил өчен!

Россия халкы үз ватанын һәм кыйммәтләрен Көнбатыш йогынтысыннан саклаячак. Аның сүзләренчә, элегрәк тә башка илләрнең өстенлеккә дәгъва итү теләген Россиянең батыр һәм нык халкы туктата алган.

– Бернәрсә дә элеккечә булмаячак инде. Хәзерге көрәш мәйданы – халкыбыз һәм Россия өчен көрәш кыры ул. Безнең кыйммәтләр – кешеләрне ярату, мәрхәмәт һәм шәфкатьлелек. Бүген без халкыбызны, мәдәниятебезне сызып ташламасыннар өчен көрәшәбез. Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре гражданнары туган илләре белән булырга карар кылды. Безнең белән – хакыйкать, безнең белән – Россия.

Кукмарада волейбол уйнадылар

Кукмараның «Барс Арена» спорт комплексында республиканың сәнәгать предприятиеләре һәм авыл районнары арасында Татарстан Волейбол федерациясе президенты IX кубогының финал уеннары узды. Уеннарны ачу тантанасында Дәүләт Советы Рәисе, Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Дәүләт Советы Рәисе, уеннарда катнашучыларны, район җитәкчелеген, ярышларны оештыручылар һәм җанатарларны сәламләп, әлеге спорт төренең бик нык популярлашуын билгеләп үтте. «Волейбол безнең республикада гына түгел, тулаем илдә дә актив үсә. Хәзерге вакытта Кубокның предприятиеләр һәм авыл районнары арасында иң зур волейбол турнирына әйләнүен шикләнмичә әйтергә мөмкин, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Ярышларда катнашучылар үзләренең коллективы, районы, уку йортлары мәнфәгатьләрен ничек якларга кирәклеген күрсәтә».

Ул шулай ук хәзерге вакытта республикада әлеге спорт төре белән шөгыльләнү өчен барлык шартлар тудырылуын искәртте. «Моннан бер атна элегрәк кенә Казанда тагын бер зур турнир – I Гомуммроссия Мәктәп волейбол лигасы тәгәлләнде», – дип искә төшерде ул.

Волейбол федерациясе президенты журналистлар белән дә аралашып алды. Аның әйтүенчә, команда спорты берләштерә, ватанпәрвәрлек рухы тәрбияли. «Бүгенге катлаулы чорда егетләрнең һәм җанатарларның җыелышып алуы, хәтта балалары белән яшь аналарның да залга килеп утыруы коллективизм, бердәм команда рухы турында сөйли, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Минемчә, волейболны, Татарстан Мәктәп волейбол лигасын, авыллар һәм сәнәгать предприятиеләре арасындагы ярышларны үстереп, без республикада яшәүчеләрнең сәламәтлеген ныгытабыз, аларга спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирәбез».

Волейбол федерациясе президенты кубогына финал ярышларында барлыгы 8 команда катнашты. Сәнәгать предприятиеләре арасыннан – «Татхимфармпрепараты», «Газпром трансгаз», «Татэнерго», «Казань-восток-сервис». Ә инде авыл районнары командалары арасында Саба, Мамадыш, Актаныш һәм Буа районнарының үзешчән спортчылары ярышты.

Сүз уңаеннан, мондый ярышлар 2014 елдан бирле үткәрелеп килә.

Парламент тыңлаулары үткәрелә

«2023 елга һәм планлары 2024, 2025 елларга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын карап тикшерү буенча парламент тыңлаулары 7 октябрьдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Кече залында үткәрелачәк. Башлана – 10.00 сәгатьтә.

Закон белән Дәүләт Советының рәсми сайтында (https://gossov.tatarstan.ru) танышырга мөмкин.

КИТЕРЕП БИРӘЛӘР

РОССИЯДӘ МАРКЕТПЛЕЙСЛАР КӨННӘН-КӨН ПОПУЛЯРЛАША БАРА

Якын киләчәктә кибеткә барып товар алу да сирәк күренешкә әверелергә мөмкин. Ник дигәндә, бүген кирәкле әйбереңне кулдан төшмәгән телефон аша гына заказ биреп тә алып була. Рәсми саннарга ышансаң, хәзер Россиядә 65 миллионлап кеше маркетплейслардан файдалана. Бер ел эчендә Татарстанда да интернет мәйданчыкларда сату итүчеләр дә, сатып алучылар саны да арткан.

Күршебез Лилия Зарипова йортыбызның беренче катында урнашкан интернет-кибетнең товар тапшыру пунктына тузан төшерми.

– Соңгы арада ялкаулыкка чыктым. Кирәк әйберне телефон аша гына заказ бирәм да товарны шушында төшәм дә алам. Йорт кирәк-ярагын, кер юу порошокларын да. Көнкүреш техникасы да алып караган бар. Гадәти кибеткә азык-төлек алырга гына йөрибез хәзер. Бил беренче сыйныфка укырга керүче кызыбызга мәктәп кирәк-яракларының бер өлешен дә интернет-кибеттән алдык. Кибет бәяләре белән чагыштырып караган идем, 5 мең сум чамасы акчаны янга калдырабыз икән, – ди Лилия.

Data Insight агентлыгы мәгълүматларына караганда, быелның алты аенда Россиядә электрон сәүдә күләме 2,2 триллион сумга җиткән. Бу, алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 1,5 тапкыр күбрәк. Белгечләр ел ахырына интернет товар әйләнеше ике тапкыр артыр дип фаразлыйлар. Бер ел эчендә Татарстанда интернет аша заказ биреп кайтарткан товарларны тапшыру пунктлары саны да ике тапкыр артып, 6321гә җиткән.

Билгеле булганча, бүген республикадагы эшмәкәрләрнең дә кубесе нәкъ менә маркетплейслар аша сату итә. Беренче ярты еллыкта онлайн рәвештә сәүдә итүче республика эшмәкәрләре саны 100 тапкыр арткан. Чагыштыру өчен: узган елның 1 гыйнварында Татарстанда интернет мәйданчыкларда сәүдә итүче 321 эшмәкәр исәпләнгән булса, бүген аларның саны 32 меңгә җиткән. Ел башыннан бирле алар бу эшчәнлектән 25 миллиард сум табыш алган.

Татарстан Президенты каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрид Габделганиев сүзләренә караганда, ел азагына кадәр маркетплейслардан алынган табыш күләме 50 миллиард сумга кадәр җитәр дип көтелә.

– Татарстан Идел буе төбәкләре арасында интернет сәүдәнең активлыгы буенча алдынгы рәткә чыкты. Интернет сәүдә бүгенге көндә катлаулы шартларда да үсүен дәвам итә. Белгечләр быел маркетплейслардагы сатучылар саны 63 процентка артып, 2,8 миллиард товар бәрәмлеге тәшкил итәр дип фаразлый, – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда.

Казанда булачак әниләр өчен киемнәр тегүче Анна Скрябина да хәзер товарларын интернет аша сата башлаган. Ике ел элек үзе яшәгән йорт янында бер бүлмә арендалап, кечкенә генә кибетен булдырган.

– Узган ел үзем теккән киемнәрне «Wildberries» аша сата башладым. Шуннан соң минем товарларны сатып алучылар саны бермә-бер артты. Маркетплейска товар урнаштыруның нечкәлекләре, мәшәкате булса да, үз эше булган кешеләр өчен аны бик отышлы дип таптым. Бик күп чыгымнарың кими, товарыңны таныту да җиңелрәк, – ди Анна.

pixabay.com

Маркетплейслар тиз һәм уңайлы булулары белән беррәттән, халыкка яңа эш урыннары булдыруы белән дә алдыра. Узган ел интернет сәүдә мәйданчыкларында 55 меңнән артык вакансия исәпләнгән. Шуларның 19 меңе – сатучы, 20 меңе – курьер, 15 меңе – склад хезмәткәре, калган меңнән артыгын маркетинг белгечләре тәшкил итә. Фәрид Габделганиев сүзләренә караганда, бүген бирдә эшләүчеләр уртача 63 мең сум хезмәт хакы ала.

– Без узган ел электрон сәүдә мәйданчыгына чыккан оешмалар арасыннан очраклы рәвештә 100не сайлап алдык та Салым федераль хезмәте аша алардан килгән салым күләме турында белештек. Бер ел эчендә 3–3,5 тапкыр арткан, – ди ул.

Сүз уңаеннан, Татарстанда маркетплейста эшләргә теләгән кешеләрне махсус укытачак та. Ул «Демография» иккүләм проекты кысасында башкарыла. Моның өчен «Работа в России» порталында (trudvsem.ru) теркәлергә кирәк. Программада эшсезләр, 3 яшькә кадәр бала ялында булган, рәсми рәвештә эшләмәгән һәм 7 яшькә кадәрге баласы булган, 50 яшен тутырганнар, 35 яшькә кадәрге кешеләр катнаша ала. Киләчәктә бу программадан мөмкинлекләре чикле кешеләр дә файдалана алыр дип көтелә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Ә ЙӨРӘККӘ ҺАМАН 18!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– 2006 елда пенсиягә чыктым. Уем оныклар карап өйдә утыру иде. Көннәрдән беркөнне дус кызым мине «Мәскәү» спорт комплексына алып китте. Биредә сәламәтлекне ныгыту өчен күнегүләр ясаталар иде. Шул көннән мин йөзүгә дә язылдым. Аннан өлкәннәр өчен бию, гимнастика түгәрәкләре барын белеп алдым. Аларга да язылдым. Чаңгыга да бастым. Спорт тормышыма шулкадәр үтеп керде. Мин ансыз яши алмаска әйләндем. 2014 елдан пенсионерларның «Өченче буын» дип аталган спартакиадасында катнашам. Җиңүләр дә яулыйм, – ди ул. – Иң мөһиме – яшем зур инде, дип кул кушырып утырырга кирәкми. Күңелегез яшь булсын. Сәламәтлек булса, әллә ниләр эшли аласың. Ә сәламәт булыр өчен хәрәкәт җитми.

Күптән түгел 94 яшьлек бер «егет» белән танышырга туры килде. Ул да шушы сүзләрне әйткән иде. Тик тормаска куша. Вәгыйз Малиховның өенә килеп кергәч, шаккаттым. Ялгыз гына яшәүче ир-ат фатиры димәсең! Ә үзен күргәч, бөтенләй югалып калдым. Берәр бабай каршы алыр инде дисәм, Вәгыйз абый йөгереп кенә йөри икән әле. Ул режим буенча яши. Һәркөнне иртәнге биштә уяна. Бер сәгать буе гәүдәсен язар өчен күнегүләр ясый. Аннары кухнясына күчә. Тәмле итеп ботка пешерә. Көн дә бер төрлене түгел, гел төрләндереп тора. Иртәнге сигезләр тулып киткәч, урамга йөреп керергә чыга. Бер-ике сәгать йөргәч, төшке ашка кайта. Аннары тагын бераз ял итеп ала да кичке прогулкага чыгып китә.

– Үзем кебек «егет»ләрне иярттем дә скандинавия таягы белән йөрибез. Көнгә 5 чакрым җәяү йөрү бик файдалы. Ялкауланмаска кирәк. Хәзер кеше ашый да барып ята. Хәрәкәтләнү бетте. Әллә сез безнең буынны рәхәттә яшәгән дисезме? Төрлесен күрдек. Әмма яшәү дәртен югалтмадык. Әгәр рухың нык икән, кешене ялгызлык та сындыра алмый, – ди ул.

Ялгызлык дигәннән, күпләр нәкъ менә шушы «авыру» белән интегә дә инде. Кемнәрнеңдер балалары ташлап китә, кайберәүләр газизләрен иртә югалта. Кадерсез көнгә төшкәннәре дә бар. Шөкер, күпчелек өлкәннәр ялгыз түгел. Дәүләт программасы ярдәме белән аларны социаль хезмәткәрләр тәрбияли. Әби-бабайлар аларга бик рәхмәтле. Балтач районының Алан авылында яшәүче Гөлчәчәк Гафурова да биш әби һәм бер бабайның үз кызына әйләнгән.

– Мин үземә кушылган сәгать буенча гына эшләмим. Авылдашларымның хәлен еш белешәм. Алар ялгызлыктан курка. Авырый башласалар, балалар кайтып өлгерерме, дип борчылалар. Олылар белән эшләү тәҗрибә дә бирә, яшәргә дә өйрәтә. Үзебезнең дә картаясы бар бит. Алда ни көткәнне берәү дә белми, – ди ул. – Әбиләрем мине үз кызыдай күрә. Үземдә генә яшәтер идем, диюче дә бар.

Бу көннәрдә өлкәннәр аеруча кадер-хөрмәттә. Аларның күбесен лаеклы ялга киткән эш урыннарына чакырып кунак итәләр, күчтәнәчләр өләшәләр, бушлай кино-концерт күрсәтәләр, парк-скверларда алар өчен төрле чаралар уза, чәчләрен кистереп, мунчада юынып та кайта алалар. Ә аларда бер теләк – бәйрәмдә генә түгел, калган көннәрдә дә наз, җылы сүз, ярату кирәк аларга! Без аларны шул бәхеттән мәхрүм итмәсәк иде.

Хөрмәттә яшәгез!

Халыкара өлкәннәр көне уңаеннан Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира ЗАРИПОВА аларга газета аша мөрәҗәгать итте.

«Күркәм традиция буенча октябрьнең беренче көнендә без иҗтимагый әһәмиятле датаны – Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтәбез, – диелә мөрәҗәгатьтә. – Бүген өлкәннәрнең күп кенә проблемаларын республиканың социаль тармагы уңышлы хәл итә. Социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү системасының эше билгеле бер кешенең шәхси мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү генә түгел, ә тулаем алганда олы яшьтәге кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрү өчен дә оештырыла. Республикада интернат-йортларда яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга аерым игътибар бирелә. Хәзерге вакытта 26 интернатта 1800дән артык өлкән кеше яши.

Өлкән буын гражданнарының мәдәни-ял эшчәнлегенә аерым игътибар бирелә. Республикада пенсионерларны компьютерда эшләргә өйрәтү буенча программалар тормышка ашырыла, спартакиадалар, турнирлар, фестивальләр үткәрелә. Өлкән яшьтәге кешеләрнең мәнфәгатьләрен һәм теләкләрен күзәтеп торырга һәм аларның үтенечләренә вакытында җавап бирергә безгә республиканың иҗтимагый оешмалары: Татарстан Республикасы ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы, «Россия пенсионерлары берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлекчәсе һәм «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика иҗтимагый оешмасы белән тыгыз элемтәләр ярдәм итә.

Картлык һәрберебезне көтә. Өлкәннәргә юлны узарга ярдәм иткәндә, транспортта урын биргәндә, өлкән кешеләрне кызганганда, хөрмәт иткәндә, әби-бабайларыбызның күңелләре җылылык белән тула. Хөрмәтле ветераннар! Без сезгә көн саен мохтаҗбыз. Сез безнең өчен әхлак, тәүфыйк, тәрбия үрнәге булып торасыз. Хезмәтегез, дәүләтебезнең үсешенә керткән өлешегез, бүген безгә күрсәткән батырлык дәресләре өчен зур рәхмәт. Сезгә корычтай нык сәламәтлек, озын гомер телим, табыннарыгыз мул, көннәрегез аяз булсын, якыннарыгызның кадер-хөрмәтен тоеп яшәргә язсын!»

Күчемсез милеккә хокук кирәк

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аңлату эшләре

Бу бик мөһим, диләр Татарстан Росреестрында һәм аңлату эшләре дә алып баралар.

Әлеге оешманың җитәкчесе урынбасары Нияз Галиәкбәров әйтүенчә, республикабызда кайчандыр кадастр исәбенә куелган объектлар бик күп. Әмма Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында (ЕГРН) аларга хокуклар турында берниндди дә мәгълүмат юк, чөнки тегеяки бу сәбәп аркасында хуҗалары бу гамәлне кирәк дип тапмаганнар. Өстәвенә 1998 елның 1 гыйнварыннан хокук рәсмиләштерү тәртибе дә үзгәреп, эш тулаем техник инвентарьлаштыру һәм җирле үзидарә органнарына йөкләнә. «Кайбер гражданнар йортларыннан, участокларыннан бик күп еллардан бирле файдалана, – ди бу җәһәттән Нияз Галиәкбәров. – Әлбәттә инде, аларны беркем дә борчымый. Шуңа күрә әлеге объектларга хокукларын теркәү кирәклеген башларына да кертмиләр. Дөрес, күбесендә милекнең аларныкы икәнлеген дәлилләүче туксанынчы елларда бирелгән документлар бар. Алар шулай ук юридик көчкә ия, әлеге объектларны хуҗаларыннан беркем дә тартып ала алмый. Әмма бүген милеккә хокукны яклау өчен мәгълүматларны бердәм дәүләт реестрына кертергә кирәк».

Бу, чыннан да, ни өчен кирәк? Әлеге сорауга җавап бирү йөзеннән Нияз Галиәкбәров түбәндәге сәбәпләрне атый.

Беренчедән, милеккә хокук дәүләт теркәве узганнан соң гына башлана. Бу процедураны үтмәсә, объект хуҗасы милкен бүләк тә итә алмый, сатып җибәрергә дә, залогка куярга да, арендага бирергә дә хокукы булмый. Ә тормыш булгач, үзегез беләсез, төрле хәлләр килеп чыгарга мөмкин.

Икенчедән, хокукны теркәү ул – милкеңне мошенниклардан саклау дигән сүз. Бүген алдап-йолдап үзләштерүләр саны артканнан-арта. Мәсәлән, ялган документлар ясаучылар сезне төрле юллар белән йортыгыздан яки бакчагыздан мәхрүм итәргә мөмкин. Әгәр дә милеккә хокук бердәм дәүләт реестрында теркәлсә, хуҗа кеше үзеннән башка берниндди эшләр алып бармаска дип таләп куя ала. Моннан тыш, аның үзе турында барлык мәгълүматлар да реестрга кертелә. Бу исә, берәр аңлашылмаучылык килеп чыкса, белешмәләрне тиз арада хуҗасына җибәреп, дөреслекне ачыкларга мөмкинлек бирә. Шулай ук күрше биләмәләр белән чикләр турында низаг килеп чыгудан коткара.

Өченчедән, әгәр участок дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кулланылса (мәсәлән, юл төзелешенә), хокукы теркәлмәгән милек өчен компенсация бирелми. Шулай ук табигый һәм техноген катаклизмнар, янгыннар, су басу очракларында да ярдәм итәргә ашкынып торучы булмас. Компенсация, иминият түләүләре бары тик хокукы теркәлгән милек өчен генә биреләчәк.

Дүртенчедән, документлар күп очракта югалырга мөмкин, аларны торгызу бик катлаулы, гадәттә барысы да суд аша эшләнә. Ә реестрда теркәлгән очракта аларның күчермәләрен теләсә кайсы вакытта алырга мөмкин.

Бишенчедән, милеккә хокукны теркәмәүнең сәбәбе күп вакытта салымга бәйле. Кеше кесәсеннән артык акча чыга дип курка. Әйтергә кирәк, хәзер муниципалетлар тарафыннан мондый объектларны, аларның хуҗаларын эзләү эше җайга салынган. Табылган очракта мәгълүмат Росреестрга җибәрелә, әмма бу гамәл дәүләт теркәве булып саналмый, бары тик салым салу өчен нигез булып кына тора.

Хуҗасы табылмаган очракта җирле үзидарә органнары, мондый объектларны хуҗасыз дип танып, муниципаль милек итеп тә рәсмиләштерә ала.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

САН

Татарстан Росреестры мәгълүматлары буенча, бүген республикада Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында 4,5 млн күчемсез объект турында мәгълүмат бар. Шуларның 853 меңенә хуҗалары тарафыннан хокук теркәлмәгән. Бу исемлектә 333,5 мең җир участогы, 196 мең торак бина, 117,5 мең торак йорт, 40 мең гараж, 37 мең бакча йорты, 4 мең төзелеп бетмәгән объект исәпләнә.

«Мин татарча укыйм»

ӘНИЕМ ЯЛГЫШМАГАН

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бүген татар мәктәп һәм гимназияләренең исеме җисеменә туры киләме? Белем йортларында аралашу мохите нинди? Дәресләр туган телдә уздырыламы? Шул уңайдан газета битләрендә «Мин татарча укыйм» дигән сәхифә ачып җибәрәбез. Таныштыруны барлык фәннәрне татарча укытучы Казандагы 2 нче гимназиядән башлыйбыз. Әлеге уку йорты быел август киңәшмәсендә «Татарча онлайн мәктәп» дигән яңа проект та тәкъдим итте. Тагын нинди үзгәрешләр бар?

Көчле, милли җанлы директор Камәрия Хәмидуллина җитәкләгән татар мәктәбе үз кыйбласына тугры калганмы? Уку йорты ишеген ачканда, иң беренче күңелдә шул сорау туды. Гимназияне ике ел инде башкаладагы 13 нче гимназиянең элеккеге директоры Рамил Гайнуллин җитәкли. Хәзерге вакытта биредә 870 укучы белем ала, балалар бакчасына 160 сабый йөри. Гимназиядә барлыгы 67 укытучы белем бирә. Барысы да ике телне яхшы белә, төрек, гарәп, инглиз телләрен дә өйрәнәләр.

Без килгәндә, укучылар дәрестә иде. Тәнәфесне көткән арада вахтада утыручы Люция апа Салихова белән сөйләшеп алдык. Заманасында татар мәктәпләрендә директор һәм урынбасар булып эшләгән милли җанлы кеше ул. Пенсиядәге ханым монда 11 ел тәртип саклый. Һәр баланы исеме белән белә.

– Камәрия Зиннуровна миңа: «Син монда вахтер түгел, генераль директор», – дигән иде, менә шуңа алданып утырам, – дип елмайды 72 яшьлек Люция ханым. Иң беренче булып балаларның әдәбенә тукталды ул. Әллә кайдан «исәнмесез!» дип исәнләшәләр икән үзләре. Тәртипсезләргә монда урын юк. Мәктәпкә балаларны сагынып киләм, ди.

– Татарча ишетү генә түгел, монда шул казанда кайныйсың. Дәресләр татарча уза. Кайбер укучылар үзара русча да аралаша. Рус егетләре дә бар. Өченче ел Кирилл, быел Александр укып бетереп чыгып китте. Александрның әнисе: «Саша татар инде ул, үзебез татармы, русмы, хәзер инде белмибез», – ди. Өйдә рус телендә сөйләшсә дә, гадәтләр татарчага әйләнгән, – ди Люция апа.

Балалар татарча аралаша, шул ук вакытта русча сүзләр дә яңгырап китә. Мәктәп ишегалдында күзәтелә бу. Балаларын мәктәпкә озатучы әти-әниләрне дә туктатып сөйләштек. Алар ул-кызлары белән татарча аралаша. «Бу гимназияне сайлаганга, шатланып туя алмыйбыз. Уку да, тәртип тә канәгатьләндерә», – диеште алар.

«Татарча онлайн мәктәп»

Гимназия менә шундый исемдәге яңа проект тормышка ашыра башлады. Төрле фәннәрдән төшерелгән татарча видеодәресләрне хәзер башка төбәкләрдәге укучылар һәм укытучылар да файдалана. «Татарча онлайн мәктәп» платформасын төзүче, директорның мәгълүматлаштыру буенча урынбасары Рөстәм Гыймранов әйтүенчә, математика, физика, химия һәм башка фәннәрдән барлыгы 200дән артык видео дәрес төшерелгән. Бу эш алга таба да дәвам итәчәк. Дәресләр БДИда белгеч булган тәҗрибәле укытучылар тарафыннан төзелгән.

– Кабатланмас проект бу. Аны булдыруда коронавирус вакытында дистанткa күчү дә бер этәргеч бирде. Шул ук вакытта чит төбәкләрдә дәреслекләр табу проблемасы да бар, булганнары да искерә. Шул хакта да уйладык. Хәзерге вакытта Самара, Чиләбе, Свердлау өлкәсе мәктәпләре әлеге онлайн дәресләрдән файдалана. Бу – өстәмә чыганак. Платформага теркәлергә кирәкми, аннан теләсә кем куллана ала, – дип аңлатты Рөстәм Гыймранов.

Татарстандагы район һәм шәһәр мәктәпләре дә әлеге проект белән кызыксына икән. Ләкин әлегә районнар буенча йөреп җитешә алмыйбыз, диделәр. Белемен яңартырга теләгән һәркем өчен дә файдалы булачак ул. Иң мөһиме: татар телен белергә кирәк.

«Бер авырлыгы да юк»

Гимназиядә укучылар татарча уку турында әнә шулай диде. Киресенчә, татарча уку аларга фәннәрне тагын да яхшырак үзләштерергә мөмкинлек бирә.

– Өйдә дә, мәктәптә дә татарча сөйләшәбез. Урамда – ике телдә. Бигрәк тә татар теле дәресләрен яратам. Бу мәктәптә 1 нче сыйныфтан бирле укыйм, – диде 6 нчы сыйныф укучысы Әдилә Зәйнуллина.

Алсу Мирзаева бакчада татар төркеменә йөргән. Шул вакытта ук әнисе: «Кызым, мин сине татар мәктәбенә бирәм», – дип әйтеп куйган. Әни бик дөрес эшләгән, ди Алсу.

Без кергәндә, 8 нче сыйныфта физика дәресе иде. Сыйныфта – 20 бала. Барысы да татарча аралаша. Дәреслекләр дә татарча. Укытучылары Рәдиф Сафиуллин бер ел элек Балык Бистәсе районыннан күченеп килгән.

– Дәресләрне татар телендә алып барам. Барысы да туган телдә фикерли. Кайберләре бигрәк әдәби итеп сөйләшә, мин алар кебек сөйләшә белмим. Татар теле шундый бәрхет тел бит ул. Барыбызга да менә шул матурлыкка омтыласы иде, – ди Рәдиф Сафиуллин.

10 нчы сыйныфта татар теле әдәбияты дәресе иде. Әлеге фәнне алып баручы Гөлия Шакирова гимназиядә 18 ел эшли икән инде. Аннан балаларның китап уку-укымавы турында сораштык.

– Укыйлар, иң мөһиме – аңлап укыйлар. 5 нче сыйныфтан әсәрләргә анализ ясарга өйрәнә башлыйбыз. Әдәбият әдәпкә, тормышка өйрәтә, – диде Гөлия Шакирова.

БДИ куркытмый

– Бездә, татар теле кирәкми, дигән бер генә әти-әни дә юк. Киресенчә, тагын да күбрәк татар мохите булдырылсын иде, диючеләр бар. Татарча укыганга сынауны бирә алмадым, диючеләрне ишеткән юк. Югары сыйныфларда терминнарны өч телдә дә өйрәтәбез. Нәтиҗәләр ил һәм республика буенча уртача күрсәткечләрдән югарырак. Мәскәү, Санкт-Петербург вузларына кергән яшьләр дә бар. Бер укучыбыз быел Төркиядә белем ала, – ди Рамил Гайнуллин.

Директор белдергәнчә, гимназиядә мохит – татарча. Әти-әниләрнең барысы да татар телен сайлый. Татар теле атнага – ике, әдәбият бер дәрес керә. «Мин биш сәгать укытабыз дип мактана алмыйм. Үзем татар теле укытучысы буларак әйтәм моны. Бөтен эшчәнлек татар телендә алып барылгач, укучылар башка фәннәрдә дә татарча җавап бирәләр. Әмма укытучы буларак, әдәбиятка сәгатьләр күбрәк кирәк. Татар теленең матурлыгын, байлыгын ачып салу өчен бу гына җитми дип саныйм», – ди ул.

Быел республикада татар теле сынавын нибары бер генә укучы бирде. Ни өчен сездән бер генә укучы да сайламады, дип тә сораштык аннан.

– Узган ел бер укучы филология юнәлешенә укырга керде, быел андыйлар юк. Балалар үзләрен татар телен бирү дәрәҗәсен төрле бәйгеләрдә дәлилләп тора. Аларда ниндидер мохтаҗлык юк. Әмма патриотик як та бар. Әгәр туган телдән имтихан сайласалар, әлбәттә, сөенер идем. Әлеге сынауны бирүче балаларга вузга кергәндә төбәк дәрәҗәсендә өстәмә баллар бирсеннәр иде. Андый укучыларның тырышлыгын бәяләү кирәк, – дигән фикердә ул.

Ничек үзгәртергә?

Директор белән әңгәмә барышында мәктәпләрдә унбер ел буе татарча укып та, берни белмәгән укучылар турында да сүз кузгаттык.

– Директор, урынбасар, коллективтан күп нәрсә тора. Бу вазгыятьне татар теле укытучылары проблемасы итеп карарга кирәкми. Алар болай да күпне кичерде. Эзләнү, яңарыш чорында килеп туган кыенлыкларны бергәләп чишәргә кирәк. Бер генә мисал китерәсем килә. Күпләр IT юнәлешләр буенча белгечләр әзерләүче Иннополиста укучылар татар телен белми дип уйлый. Әмма бу алай түгел, анда татар теле буенча төрле проектлар тормышка ашырыла. Бик әйбәт сөйләшә балалар. Бу – команда тырышлыгы, – ди Рамил Гайнуллин. – Күпчелек әти-әниләр инглиз телендә аралашу мохите тудырылган хосусый бакча, мәктәпләрне сайларга тырыша. Ләкин соңгы берничә елда аларның туган телдә белем бирә торган мәктәпләргә игътибары артты. Бу – шатлыклы күренеш. Инглиз телендә укыту – бер, ана телендә – икенче мәсьәлә. Галимнәр, ана телендә укыган бала күбрәк ачыла, дип исбатлый. Безнең эшчәнлек тә шуңа корылган. Барлык балалар да сәхнәдә чыгыш ясый. Укучылар татар телен генә түгел, русчаны да яхшы белә. Башка телләрне дә теләп өйрәнә.

Фән теле турында да уйлана директор. Аның әйтүенчә, нинди фән, әле бездә гади итеп тә сөйләшә белмиләр, диючеләр дә булыр. «Татарлар арасында ил, дөнья күләмендә танылган галимнәр бар. Аларның язган мәкаләләрен, ачышларын татарча бастырсак, башка галимнәр дә шуңа карап, үзләренекен алып барыр, студентлар фәнни эшләрдә кулланыр иде. Укымышлы кеше бу ачыш турында укыр өчен татарча өйрәнәчәк», – дип ышана ул.

Татар теле мәсьәләсе күпме генә күтәрелсә дә, аның алдында зур проблема тора дип уйламый Рамил Гайнуллин.

– Кечкенә чактан татар мохитендә үскәнгәме, шәһәрләрдә күп йөргәнгәме, кем нинди телдә сөйләшүенә игътибар итәм. Чит төбәкләрдә дә, Татарстанда да менә дигән итеп татарча сөйләшәләр. Тел бетә дип уфтанырлык сәбәпләр күрмим, фаҗига ясарга кирәкми. Булган хәзинәләрне саклап үстерергә кирәк. Бүген – цифрлаштыру заманасы. Укыту онлайн мәктәпкә, гаджетка калсын димим, укытучыларны роботка алыштыру яклы да түгелмен. Әмма укучыларга сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү өчен укытучылар коллективы заман белән бергә атларга тиеш, – ди Рамил әфәнде.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Рамил БАҺАВЕТДИНОВ,
КФУ студенты, гимназиянең БДИны 399 баллга тапшырган укучысы:

– Татар телендә уку миңа беркайчан да авырлыклар тудырмады: гаиләдә, дуслар арасында туган телдә аралашам, шуңа күрә мәктәп программасын да татарча үзләштерү табигый иде. Нинди телдә белем алсаң да, мәгънәсенә төшенергә кирәк, рус телен болай да җитәрлек дәрәҗәдә беләсең. Ләкин башка фәннәрне өйрәнүдә берничә телне белү, әлбәттә, отышлырак.

Минем имтихан нәтиҗәләре билгеле булгач, массакүләм мәгълүмат чараларында моңа күп игътибар бирелде, татар мәгарифенә кагылышлы мәсьәләләрдә еш искә алдылар. Татар мәгарифенең мөһимлеген ассызыклауны мин, һичшиксез, хуплыйм, әмма читтән күзәтүчеләрдә бу хәлләр ялган фикер тудырырга мөмкин иде. Янәсе, бездә бүтән мактанырлык берни дә юк. Ләкин мондый нәтиҗә чыгару төптән дөрес түгел. Чөнки БДИда югары баллар җыючы мин генә түгел идем, андый егет-кызлар ел саен була, мин тапшырган елны да бар иделәр. Шул ук вакытта мәгариф уңышларын БДИ күрсәткечләренә кайтарып калу мине шатландырмый, укучыларның олимпиада хәрәкәтендә, фәнни конференцияләрдә һәм башка шундый чаралардагы активлыгын күбрәк күрсәтергә кирәк, чөнки бу да халкыбызның интеллектуаль куәтен бик яхшы ачыклый.

Ничек кенә булмасын, татар телендә укып, югалмас өчен, телнең куллану өлкәләре киңрәк булырга тиеш. Әлеге өлкәләрне киңәйтү өчен, һәммәбезгә эшләргә дә эшләргә кирәк әле.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Президенты администрациясе, әтисе

СӘГЪДИЕВ Бәйрәмгали Исмәгыйль улы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариатының регламент чараларын оештыру бүлеге мөдире Сәгъдиев Альфред Бәйрәмгали улының авыр кайгысын уртаклаша.

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

КУКМАРА КЫЗЫКЛАРЫ

Менә сиңа Ленька!

«Каршы ала, озатып кала поездларны Кукмара» дип җырлаганнарын ишетмәгән кеше юктыр. Вокзалда каршылау, озатып калу – безнең як халкы өчен күркәм гадәт. Моннан байтак еллар элек Казаннан, партия өлкә комитетыннан килеп төшәләр, ә рәсми каршылаучы юк! Көнозын вокзалда арлы-бирле йөрүче, акылга зәгыйфьрәк Ленька-Трактор (аны шулай дип йөртәләр иде) боларны күреп ала, тиз генә райкомга кадәр озата төшә һәм килүчеләрнең сумкаларын идеология бүлеге мөдире Һади Шаһиевич бүлмәсендәге өстәлгә шап итеп куя. «Всего вам хорошего», – ди дә чыгып китә бу. Кунакларның Ленька белән килүен күреп өне алынган мөдир утырган урындыгыннан егылып төшәрдәй була, бераздан райком секретареннан да яхшы гына «өлеш тия» үзенә.

Аңлату

Райком бинасы райтопсбыт котельныеннан җылытыла иде. Җылытуның исә һич рәте юк, пәлтә киеп утырырлык. Шахмаевны беренче секретарь Булатов үзенә чакырта. Шахмаев пәлтәсен кабул итү бүлмәсендә салып, куркып кына кабинетка үтә. Беренче моңа кулы белән ишарәләп урын күрсәтә, үзе исә телефоннан сөйләшергә тотына, каядыр чыгып та керә, аннан өстәлдәге кәгазьләрен актара башлый, тагын телефонга ябыша… Тирләп-пешеп кергән Шахмаевның тешләре тешкә бәрелә башлый. Шулчак Булатов әйтеп куя: «Йә ничек? Менә шуның өчен – бездәге хәлләрне аңлату өчен чакырган идем сине». Шахмаевка инде: «Аңладым, Атлас Минхәерович», – диюдән башка чара калмый.

Сәбәбе «җитди»

Күп еллар авыл хуҗалыгы идарәсендә җитәкчелек иткән Мәснәви Галиевкә райком бюросы бер эш куша. Соңгы вакытта нык кына «төшергәли» башлаган колхоз рәисе янына барып, эчүнең сәбәбен ачыкларга кирәк. Урында эчкече рәис тиз генә ачыклык кертә:

– Менә, Мәснәви Галиевич, иртүк фермага барам, сыерларга салам кертелмәгән, маллар кычкыра, сыер савучылар килеп җитмәгән, ферма мөдире мине күрүгә качкан. Шуннан соң үземнең дә башка суга, теге дөньяга китеп бармыйм тагын дип, дөньясын онытып торырга берне кәгәм инде, төштән соң шул ук фермага барсам – ну, малай, җан рәхәте, сыерлар күшәп ята, сөт заводка илтелгән – шатлыктан кул стаканга үрелә инде…

Механизатор фәлсәфәсе

Нократ Аланы белән янәшәдәге хуҗалыктан бер механизатор көнгә берничә тапкыр елга портына барып кайта икән. Кыш көнендә дә шул гадәте кабатлана.

– Кышын да пароход йөримени соң? – дип кызыксыналар моннан.

– Мин бит пароходка утырырга бармыйм, расписание карарга барам, – ди икән механизатор.

Азат САБИТОВ

ГАЛИ! ГАЛИ!

Нәҗип БӘДРЕТДИНОВ

Татарстанның халык артисты Гали Ильясов үзенә игътибарны бик ярата иде. Әгәр аны берәрсе таныса, хәтта туры итеп караса гына да, ул бу кеше белән танышып, дөньясын онытып сәгатьләр буе сөйләшеп торырга мөмкин.

Шулай беркөнне җырчы гаиләсе белән машинасын куеп өенә кайтып килгәндә, аны чегәннәр әйләндереп ала. Әлбәттә, гомере буе ресторанда эшләп, кемнең кем икәнен бер караштa аңлап алучы хатыны Сания аларның коткысына бирелми, кызлары белән юлын дәвам итә. Ә як-ягына каранып әкрен генә атлаган гаилә башлыгын тиз генә җибәрмиләр, сөйләштерә-сөйләштерә, багарга үгетлиләр. Инде җырчы болардан котылдым дигәндә, чегәннәрнең берсе абзыйга исеме белән эндәшә.

– Гали, зинһар дип әйтәм, ике минут вакытыңны җәлләмә инде.

Үз исемен ят халыктан ишеткәч, игътибар үзәгендә булырга яраткан артист бер мәлгә гаҗәпләнеп, югалып кала, шул арада төркем үзенең төп эшен башкара. Чегән кызларының иң чибәре Галидән уч төбенә биш сум акча салуын үтенә, аннары «алай түгел инде, менә болай кирәк» дип бишлекне үзе ала, күккә чөйгән булып кылана һәм бер мизгелдә акча да, чегәннәр дә юкка чыга.

Әлеге күренешне читтән күзәтеп торган хатыны ирен тирги башлый:

– Шушы яшеңә җитеп беркатлы булып йөрмәсәң!

– Ә алар минем исемне каян беләләр?

– Соң, мин кайчаннан бирле сиңа ярты Казан ишетерлек итеп урам аркылы «Гали! Гали!» дип кычкырып торам бит!

«Коня на скаку остановит», –
Дип бәян иткән бер әдип,
Урыс хатынын мактаган ул,
Янган ызбага керер дип.

Башка хатыннар да калышмый,
Якын-тирәдә булса ат,
Тота да менеп атлана ул,
Ирләр бер читтә торсын, брат!

Этнең кече йомышы турында 10 сорау

Татар теле бик бай. Шул исәптән фразеологизмнарга да. Һәм араларында бөтенләй көтелмәгәннәре дә очрый. Менә, гафу итегез, мәсәлән, «эт сигәнче» дигән сүз бар. Бик тиз, җәһәт дигәнне аңлата. Каян чыккан бу? Этнең иң тиз эшләгән эше кече йомыш микәнни? Тешләү, өрү, колак кашу, басу-ятуны эт озаграк башкарамы? Ни өчен «эт өргәнче» түгел, мәсәлән? Һәм, гомумән, эт бу эштә рекордчы, авторитет мәллә соң? Ни өчен «мәче сигәнче» түгел? Яки сыер? Кемнеңдер бу процессның вакытын исәпләгәне бармы, гомумән? Секундомер ни күрсәткән? Аның күрсәткече «эт сигәнче» дигән әйтемне куллануга җитди сәбәп була алганмы? Сораулар күп, җаваплар аз. Бәлки, халыкның үзеннән сораргадыр? Ни уйлыйсыз, халык?

Әз-мәз мәзәк



Берәр кая тиз генә барып җитәргә кирәк булса, огнетушитель тотып йөгерегез. Огнетушитель тотып йөгергән кешене бар җирдә үткәрәләр.

* * *

Бер ишек ябылса, икенчесе ачылыр, ди иде минем бабай. Яхшы кеше иде ул. Шкафларны гына начар җыя иде.

* * *

– Син шундый вакчыл, мин синең фотоңны сүзлектә «вакчыллык» дигән сүзнең аңлатмасы урынына куяр идем.

– Син, мөгаен, энциклопедия дип әйтергә теләгәнсеңдер? Сүзлектә фотолар юк, энциклопедиядә генә була ич.

* * *

– Минем өч сөяркәм бар. Һәм аларның берсе дә бер-берсе турында белми.

– Ә минем өч эшем бар. Һәм берсендә дә бер-берсе турында белмиләр.

* * *

Әгәр дә син туган авылыңны яратмыйсың икән, кардиологка күрен: йөрәгең бар микән синең?

ЧЕРНОМЫРДИНИЗМНАР

Сәясәтчеләрне кайвакыт тыңлап-тыңлап торасың да тагын бер кат тыңлап куясың. Шундый кызыклы сүзләр, Ельцин әйтмешли, «загогулина»лар әйтеп куялар – теләсә кайсы сатирик көнләшер! Бу өлкәдә беренчелек, әлбәттә, Россиянең элеккеге Премьер-министры Виктор Черномырдинда. Степаныч әйткән фикерләрнең кайберләре – сөйләм теленең чын энҗе бөртекләре! Черномырдин агай әйләнеп ятсын әле, ә без аның иң популяр төртмәләрен искә алыйк.

- Что говорить о Черномырдине и обо мне?
- Надо контролировать, кому давать, а кому не давать. Почему мы вдруг решили, что каждый может иметь?
- Мы так жить будем, что наши внуки нам завидовать будут.
- Вечно у нас в России стоит не то, что нужно.
- Правительство – это не тот орган, где можно только языком.
- Президент сказал: «Есть контакт!» Будем есть контакт.
- Меня всю жизнь хотят задвинуть. Задвигал только таких ещё нет.
- Хотели как лучше, а получилось как всегда.
- Мы выполнили все пункты от «А» до «Б».
- Наша непосредственная задача сегодня – определиться, где мы вместе с вами находимся.
- Я бы не стал увязывать эти вопросы так перпендикулярно.
- У кого руки чешутся – чешите в другом месте.
- Принципы, которые были принципиальны, были не принципиальны.
- Раньше полстраны работало, а пол не работало, а теперь… всё наоборот.
- Наш народ будет жить плохо, но не долго.

Мач әйткән!

ОСКАР УАЛЬД,
Ирландия фәлсәфәчесе

Кайберәүләр үзләренең килүләре белән бәхет китерә, ә кайберәүләр – китүләре белән.

Замана тизәйткечләре

Айваз САДЫЙРОВ

Сары сагыш дип сайраган саллы Салаватны санлаучылар һәм аңлаучылар саладамы, әллә каладамы?

Зәйнәб зәбәрҗәттәй, зилзиләдәй зәвыксыз заманадан зарланмыйча, зур залларны зәвык белән затландыра.

Гөлназ Сәфәрова сафсата сатканда сөйләвен саф сапфир төсле Асафка сиптерә.

Ринат Рәхмәтуллин рәхәткә рәхмәт әйтми ул.

Зәркән кебек затлы Зәйнәб, зар елыйлар гайбәтчеләр – булмый чәйнәп.

«Ватаным Татарстан» – вәт аның татары оста!



Фотофакт

Кытайның Гуанчжоу шәһәрендә үзенчәлекле урын бар. Дүрт полосалы автомобиль юлы бер агач йортны урап уза. Эш шунда ки, бу өйнең хуҗасы – Льянг исемле ханым – торакны дәүләткә сатарга теләмәгән. Трассаны ясаганда аңар 186 мең доллар компенсация һәм ике фатир тәкъдим иткәннәр, әмма ул 4 фатир сораган. Ахыр чиктә 40 квадрат метрлы бу йортны трасса урап узган. Шунысы кызык: бу юлны төзегәндә 47 шәхси зат һәм 6 оешманың объектларын сүткәннәр, ә бу хатын үзенекенә каткан. Аның каравы хәзер бу җиргә туристлар агыла ди. Көтмәгәндә бөтен дөньяга популяр булып куйган йортны… һәм олы юлның тузанын иснәп гомер итүче үзсүзле хатынны күрергә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 344

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+